УДК 821.512.145-2

*Д.Р. Фәрдиева*

# К. ТИНЧУРИН ПЬЕСАЛАРЫНДА ПСИХОЛОГИЯ ҺӘМ ГЕРОЙЛАРНЫҢ ЭЧКЕ ДӨНЬЯСЫН ЧАГЫЛДЫРУ
## («Соңгы сәлам» һәм «Сүнгән йолдызлар»)

Творчество К. Тинчурина составляет гордость и славу татарского народа. Его можно поставить в ряд первостепенных драматургов как создателя неувядаемых шедевров, оказавших влияние на развитие татарской драматургии. Время не стерло с произведений Тинчурина свойственных им красок, их общечеловеческую сущность, неумирающую идейно-эстетическую ценность. В его пьесах изображаются обычные ситуации с обыкновенными людьми, драмы которых уходят в быт и человеческую психологию.

**Ключевые слова:** пьеса, психология, герой, внутренний мир, характер.

Кәрим Тинчуринның драматургия өлкәсендәге эшчәнлеге 1911 елда башлана. Сәхнә әсәрләре буенча иҗади казанышлар, яңа юнәлешләр һәм жанрларның күбесе аның исеме белән бәйле. Сәхнәгә яңа темалар һәм образларны башлап күтәрүче дә ул. Аның яңалыкка омтылышы татар театры үсешендә зур урын алып тора, ә К. Тинчурин үзе татар сәхнә сәнгатенә җаны-тәне белән бирелгән фидакарьлек үрнәге булып санала. К. Тинчурин иҗаты халыкчанлык белән сугарылган, шуңа күрә аның сәхнә әсәрләре әле бүген дә татар тамашачысы күңеленә ләззәт, хозурлык өсти. К. Тинчурин пьесаларына жанрлар төрлелеге хас. Шул ук вакытта аны әхлакый-психологик проблемалар да кызыксындыра. Ул үз геройларының язмышын чынбарлыкка якын итеп, тирәнтен тасвирлый.

Әлбәттә, драматург һәм режиссер К. Тинчурин үзе тудырган образларның эчке кичерешләрен сәхнәдә ачуның әсәрдә урын алган эш-хәрәкәтләр, көрәш, конфликтлар аша гына тормышка ашырылуын яхшы аңлый. Аның үзенчәлеге шунда, ул үз заманы тормышына үтеп кергән һәр яңалыкны бик тиз тотып ала һәм аны үз пьесаларындагы образлар, аларның каршылыклы мөнәсәбәтләре ярдәмендә яктыртуга ирешә.

Үз персонажларының шәхси дөньясын ачуда К. Тинчурин игътибарын аларның хисси халәтләренә, эчке кичерешләренә һәм психологиясенә юнәлтә. Аның геройлары калку һәм күпкырлы. Психологик яктан киңкырлы социаль типларны сурәтләүдә драматург төрле чаралардан файдалана, ягъни алар персонажларның монологлары, сөйләме, интонацияләре, үзара әңгәмәләре һәм үз-үзләрен тоту нормалары аша яктыртыла. Ул үз геройларын чор таләпләреннән чыгып кына түгел, ә кешеләргә хас шәхси үзенчәлекләрне дә истә тотып гәүдәләндерә.

К. Тинчурин кеше психологиясен, аның эчке дөньясын,

күңелендә барган катлаулы каршылыкларын дөрес итеп күрсәтә белә. «Соңгы сәлам» (1916) һәм «Сүнгән йолдызлар» (1923) пьесаларында ул үзәк персонажлар итеп көчле характерлы, кеше хәлен аңлаучы һәм гаделсезлеккә, хыянәткә, ялганга, кешелек дәрәҗәсен кимсетүгә һ.б.га каршы көрәшергә сәләтле, тирән хисле образларны күтәрә. Бу әсәрләрдә геройларның эчке конфликтлары беренче планга куела. Автор, икенең берсен сайлау зарурлыгы килеп туган катлаулы шартларда, геройларын хәлиткеч сынауларга дучар итә.

«Соңгы сәлам»дә коммерсант Вахит Мансуровның рус кызы Ольга Вахрушинага гашыйк булуын һәм бу аның күңелендә тирән кичерешләр, эчке каршылыклар тууга сәбәп булуын автор бөтен тулылыгы белән ача. Пьесада баш геройның эчке дөньясы бөтен тирәнлеге белән тасвирлана. Вахит ике башлангыч – Ольгага карата уянган мәхәббәт хисе һәм үз гаиләсе (ул өйләнгән була) каршында җаваплылыгы – көрәшә. Бу көрәш геройда шәхси азатлыкка омтылыш уята. Театр белгече Э. Гафарова бу хакта болай яза: «Вахит поразительным образом отчужден от мира, в котором он живет, он полностью и без остатка предоставлен самому себе, и никакие успехи не в силах разлучить Вахита Мансурова с самим собой – тревожным и мающимся от непостижимой маеты. В тайну героя нет ходу никому, даже самым близким» [Гафарова, с. 11]. Мансуровның психологиясе аның үз гаебен тануы һәм үз хисләрен йөгәнләү процессында – пьесаның чишелеш ноктасына җиткәч – аның тәүбәгә килүендә ачыклана.

Әлбәттә, К. Тинчуринның герое катлаулы һәм каршылыклы характерга ия, ул үзенең яшәү мәгънәсен югалта. Драматург үз героеның газаплы кичерешләре ярдәмендә драматик конфликтлар тудыра һәм аның чишелешен дә хәл итә. Герой йомшак характерлы, ул туктаусыз икеләнү халәтендә. Болар аның котычкыч ярсулы кыланышларында чагыла. Аңлашыла ки, Вахитның каршылыклы характеры аның фаҗигасенә сәбәп була. Геройның трагедиясе шунда: ул килеп чыккан хәлләр белән я килешергә, я тормыштан китәргә тиеш була. Драматург героеның килеп туган вазгыятьтән кая барып сыенырга белми бәргәләнүен бик оста сурәтли. Ниһаять, Вахит өметсезлекнең соңгы чигенә җитә, язмышына буйсынып, үз-үзенә кул сала. Сюжеттан аңлашылганча, Вахит образы фаҗигале чишелеш өчен бирелгән. Аның аша драматург яшь, сәламәт ир кешенең мәхәббәттә үзенә үзе хуҗа була белмәгән җиңел карашлы булуын хөкем итә.

«Соңгы сәлам» пьесасы – көчсез шәхеснең фаҗигасе. Драмада аның әхлакый яктан зәгыйфьлегенең сәбәпләрен эзләү омтылышы ясала. Катлаулы эчке бәрелешләр, образларның ялган уңышлары артына яшерелгән сәбәпләрне ачыклау геройның үз-үзен юк итүенә китерә. Пьеса шәхеснең әхлакый яктан бозылуын һәм рухи таркалуын кисәтә. К. Тинчурин герое исә берничә тапкыр үзгәрергә, ба-

рысын да яңадан башларга тырышып карый. «Соңгы сәлам» пьесасының мотивы баш геройны рухи икеләнүләрдән айнырга, яңа тормышка чакыра. Автор героеның психологик халәтен сентименталь калыпта бирә. Вахит килеп туган хәлләрне җиңеп чыга алмый, үз-үзенә кул сала. Нәкъ менә рухи каршылыклар һәм икеләнү аны шушы адымга этәрә.

«Соңгы сәлам» пьесасында герой үзенең хисси үзенчәлекләренә бәйле эчке дөньясы белән шәхескә мөнәсәбәтле тышкы дөнья арасындагы каршылыкка керә. К. Тинчурин шуны таныган хәлдә, әлеге пьесасында шәхеснең эчке мөмкинлекләрен файдалану проблемасы хөкем сөргән дөнья белән кеше арасында яңа мөнәсәбәтләр урнаштыру мөмкинлекләрен табарга омтыла.

К. Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар» пьесасында персонажларның рухи кичерешләре сурәтләнә. Геройларның һәркайсы ачык яки яшерен максатларын күздә тота, аларның һәркайсында бик тирәндәге кешелек хисләре көрәшә. Образлар тулы бирелгән, һәр персонажның психологик чикләре аерым-аерым гәүдәләндерелгән. «Сүнгән йолдызлар»ның төп темасы – кеше бәхете. Әсәрдәге баш геройлар, индивидуаль психологик тип буларак, дөрес сурәтләнгән.

Надир мәхдүм образы авторның зур казанышы дип бәяләнергә хаклы, К. Тинчурин аның эчке кичерешләрен бик тирәннән ача. Надир мәхдүмгә тынгысызлык, хыялыйлык сыйфатлары хас. Ул – гадәти булмаган романтик шәхес, үзе яшәргә мәҗбүр булган заман, дөнья тарафыннан кабул ителмәгән зат. Ул изге күңелле, әмма аны үзенең физик халәте борчый. Шул ук вакытта ул горур да: үзенә кызганып караучыларны дошманы итеп күрә. Бөкре, ялгыз, дөньяга ачулы егет яшәү мәгънәсен Сәрвәргә мәхәббәтендә күрә. Яшәү белән үлем Надир өчен үз мәхәббәтенең көчлелегендә чагыла. Аның эчке матурлыгы, күңел байлыгы тышкы кыяфәте астына яшерелгән. Нәтиҗәдә Надир мәхдүм образы ярсулы һәм эчкерсез ярата белүе белән сокландыра.

К. Тинчурин Сәрвәр образы аша гаделсезлеккә каршы көрәшкә күтәрелергә җөрьәт иткән кыю татар кызын гәүдәләндерә. Шул ук вакытта Сәрвәрнең дә күңеле эчке каршылыклар белән тулы. Бер яктан, аны Надиргә димлиләр, ә икенче яктан, Исмәгыйльне сөя, үзенең бәхетен аның белән бергә булуда күрә. Шуңа күрә дә ул үз бәхете өчен көрәшергә карар кыла һәм тәвәккәлләп кискен адымга бара. Ул йөрәге кушуы буенча яши һәм сөйгәне белән бергә булырга хыяллана. Героиня, бәхетенә өмет тотып, якты хыялларга бирелә, әмма аның бу хыялларына кырыс чынбарлык каршы баса. Аны уратып алган тирәлек кызның ихтыярын, эчке дөньясын җимерә.

К. Тинчуринның «Сүнгән йолдызлар»ында Исмәгыйльнең дә эчке дөньясы катлаулы итеп сурәтләнә. Ул ягымлы, игелекле, әдәпле, әмма шул ук вакытта натурасы белән кыюсыз, йомшак характерлы. Исмәгыйль күргән төшенә ышана, ә аның төшен

бәхетсезлеккә юрыйлар, шуңа күрә егет сөйгәне Сәрвәр белән бәхетле тормышка ышанычын тәмам югалта. Аңа үз бәхете хакына көрәшү өчен кыюлык да, тәвәккәллек тә җитми. Пьесада Исмәгыйльнең эчке каршылыгы нәкъ менә шунда чагыла.

К. Тинчурин үзенең пьесаларында милли йола-гадәтләргә һәм яшәү рәвешенә яраклашып формалашкан характерларны тасвирлый. Әсәр геройлары хыялый һәм хисчән. К. Тинчурин «Сүнгән йолдызлар»дагы образларын катлаулы, каршылыклы итеп һәм шактый киң ярыткан. Автор алар үрнәгендә төрле типтагы кешеләрнең төп сыйфатларын үзара чагыштыру, тормышка карашлары ярдәмендә сурәтли һәм аларның йомшак якларын калкуландырып күрсәтә.

Әсәрләреннән аңлашылганча, К. Тинчурин характерлар гәүдәләндерү остасы. «Соңгы сәлам» һәм «Сүнгән йолдызлар» пьесаларында катлаулы һәм психологик яктан күпкырлы сыйфатларга ия кешеләрнең характерын ул яңача сурәтли. Автор геройларының күңел каршылыкларын да, үз-үзен тотышы белән эчке дөньялары тәңгәл килмәгән очракларны да оста тасвирлый.

Шул рәвешле, К. Тинчурин реалистик персонажлар дөньясын күз алдына бастыра һәм аларның күңелләрендә туган хисләрен, дөньяга карашларын тирәлектәге вакыйгаларга бәйләп яктыртуга ирешә.

**Әдәбият**

*Гафарова Э.* Пять вечеров в театре Фарида Бикчантаева // Петербургский театральный журнал. 1997. № 13. С. 11–13.

***Фәрдиева Динара Радий кызы,***
*филология фәннәре кандидаты, Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының театр һәм музыка бүлеге фәнни хезмәткәре*